МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫЩ МЭГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

14.09.2015 № под-9277/15

Казан

«Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәне раслау хакында» 01.06.2015 №6536/15 Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

«Министрлык, Дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.11.2010 ел, №906 «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2010 ел, №906 карары белән расланган гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.09.2015 № 643 карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.09.2015 ел, № 643 карары нигезендә, б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәне раслау хакында» 01.06.2015 ел, № 6536/15 боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктта «социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар» сүзләрен «иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган оешмалар»сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктта «Россия Федерациясе гражданнары, шул исәптән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләре» сүзләрен «гражданнарны, шул исәптән иҗтимагый оешмалар һәм башка социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләре»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Боерыкның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары-министр — Э.Н.Фәттахов